**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы һәм аның таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында

Йогышлылыгы югары булган кош гриппы очрагы ачыклану һәм аның таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Йогышлылыгы югары булган кош гриппы таралуын һәм аның чыганакларын бетерүгә юнәлтелгән карантин һәм башка чикләүләр кертү һәм аларны бетерү буенча профилактика, диагностика, чикләү һәм башка чараларны тормышка ашыру буенча ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 24 мартындагы 158 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм:**

1. Йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән бәйле рәвештә, аны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, әлеге Указның 2 пункты нигезендә билгеләнгән эпизоотия чыганаклары, имин булмаган зона һәм күзәтү зонасы территорияләрендә чикләү чаралары (карантин) кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) эпизоотия чыганакларын:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Димтамак авыл җирлегендәге «Латыйпов Нияз Рафаил улы» крестьян (фермер) хуҗалыгының төньяк киңлекнең 54,530949° һәм көнчыгыш озынлыкның 53,354518° географик координатларыннан 200 м радиустагы территориясе;

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Димтамак авыл җирлегендәге шәхси йорт хуҗалыгының төньяк киңлекнең 54,527806° һәм көнчыгыш озынлыкның 53,371532° географик координатларыннан 100 м радиустагы территориясе;

б) эпизоотия чыганагыннан 5 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Ютазы районының Димтамак авылын, Екатериновка поселогын, Алабакүл авылын, Тарлау авылын, Әбсәләм тимер

юл разъезды поселогын, Әбсәләм авылын, Баулы районының Уба авылын кертеп, куркыныч янау зонасын;

в) куркыныч янау зонасына чиктәш, аның чикләреннән 100 километрдан да ким булмаган радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Азнакай районы, Әлмәт районы, Баулы районы, Бөгелмә районы, Зәй районы, Лениногорск районы, Мөслим районы, Сарман районы, Ютазы районы территорияләрен кертеп, күзәтү зонасын.

3. Түбәндәгеләрне тыярга:

а) эпизоотия чыганакларында:

чир йоктырган кошларны дәвалауны;

производство (технологик) операцияләрне башкаручы персоналдан, шул исәптән кошларны караучылардан, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керә торган органнар һәм оешмалар белгечләреннән һәм чыганакларны бетерү өчен җәлеп ителгән персоналдан, эпизоотия чыганаклары дип танылган территорияләрдә яшәүче яисә вакытлыча килгән затлардан тыш, чит кешеләрнең территориягә керүен;

кошларны, яралгылы йомыркаларны территориягә алып керүне һәм чыгаруны;

кошларны күчерүне һәм төркемнәргә яңадан бүлүне;

продукт алу максатында кошларны чалуны;

чалынган кошларны һәм кошчылыктан алынган башка продукцияне территориядән читкә чыгаруны;

чир йоктырган кошлар янәшәсендә булган азыкны терлекләрнең барлык төрләре өчен территориядән чыгаруны;

кош үләксәсенең йонын һәм мамыгын йолкуны;

чир йоктырган кошлар янәшәсендә булган эш кораллары һәм башка матди-техник чараларны территориядән чыгаруны;

кошларны иректә асрауны;

йомыркаларны яралгыга салуны;

транспорт чараларының территориягә керүен һәм чыгуын (эпизоотия чыганакларын бетерү һәм (яисә) хуҗалык территорияләрендә яшәүче һәм (яисә) вакытлыча килгән затларның эшчәнлеген тәэмин итү чараларында катнашучы транспорт чараларыннан тыш);

аучылык ресурслары булып санала торган кошларны, ауны аучылык ресурслары баш санын җайга салу максатларында оештырудан тыш, аулауны;

б) куркыныч янау зонасында:

кошларны һәм яралгылы йомыркаларны территориягә алып керү һәм чыгаруны;

кошларга азык әзерләү һәм аны территориядән чыгаруны;

кошларны иректә асрауны;

авыл хуҗалыгы ярминкәләре, күргәзмәләре, сәүдә һәм кошларның, терлекләрнең башка төрләрен транспортта йөртү, күчерү һәм туплау белән бәйле башка чараларны уздыруны;

аучылык ресурсларын санын тиешле дәрәҗәдә тоту максатында аулаудан тыш, аучылык ресурслары булып торган кошларны аулауны.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы чыганакларын бетерү һәм авыру чыганагының Татарстан Республикасы территориясендә таралуын булдырмау буенча, күзәтү зонасы территориясендә уздырылырга тиешле чараларны да кертеп, чаралар планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 04 ноябрь
№ 910